ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 апреля 2018г. № 1890

Башкарма комитет Җитәкчесенең «Аукционда муниципаль мөлкәтне сату турында нигезнамәне раслау турында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 12 августындагы 585 нче карары белән расланган Аукционда дәүләт яки муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру турында нигезнамә, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 3.18, 5.24 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет Җитәкчесенең «Аукционда муниципаль мөлкәтне сату турында нигезнамәне раслау турында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 нче карарына (Башкарма комитетның 2009 елның 16 сентябрендәге 4003 нче, 2010 елның 13 сентябрендәге 5810 нчы, 2014 елның 21 июлендәге 4257 нче, 2015 елның 16 июнендәге 3637 нче, 2015 елның 4 сентябрендәге 4948 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Аукционда муниципаль мөлкәтне сату турында нигезнамәдә (алга таба – Нигезнамә):

- 2.2.7. пункттагы «басылып чыккан» сүзләрен «булган» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Сатучы, әлеге Нигезнамәнең 2.2.6., 2.2.8., 2.2.11., 2.2.13. пунктларында күрсәтелгән функцияләрне гамәлгә ашыру өчен, конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча төзелгән килешүләр нигезендә юридик затларны җәлеп итәргә хокуклы.»;

- 3.1. пункттагы «басылып чыккан» сүзләрен «булган» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.2. пункттагы «бастырып чыгарыла» сүзләрен «урнаштырыла» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.3. пункттагы «бастырып чыгарылырга» сүзләрен «урнаштырылырга» сүзләренә, «басылып чыккан» сүзләрен «урнаштырылган» сүзләренә алмаштырырга;

- 4.5.11. пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.11. Аукционда катнашу өчен алдан акча күчергән затларга акчалары түбәндәге тәртиптә кире кайтарыла:

а) аукционда катнашучыларга, аның җиңүчесеннән тыш, – аукцион йомгаклары ясалган көннән башлап 5 календарь көн эчендә;

б) аукционда катнашуга кертелмәгән дәгъвачыларга – дәгъвачыларны аукционда катнашучылар дип тану турында беркетмә имзаланган көннән башлап 5 календарь көн эчендә;

в) әлеге Нигезнамәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән юридик затлар тарафыннан сатуда җиңүченең алдан түләнгән акчасын кире кайтару сроклары бозылган очракларда, күрсәтелгән юридик затлар, срогы чыккан һәр календарь көн өчен түләнмәгән сумманың Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән һәм түләү датасына гамәлдә булган төп ставка пенясының йөз илледән бере күләмендә дәгъвачыга (ларга) пеня түлиләр.

Муниципаль мөлкәтне сату буенча аукционда җиңүченең алдан түләнгән акчасы сатып алына торган мөлкәт өчен түләү хисабына исәпләнә һәм мөлкәтне сатып алу-сату килешүе төзү өчен билгеләнгән көнгә кадәр 5 календарь көн эчендә, билгеләнгән тәртиптә Яр Чаллы шәһәре бюджетына күчерелергә тиеш.

Әлеге Нигезнамәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән юридик затлар җәлеп ителгән очракта, сатуда җиңүченең алдан түләнгән акчасы сатып алына торган муниципаль мөлкәт өчен түләү хисабына исәпләнә һәм мөлкәтне сатып алу-сату килешүе төзү өчен билгеләнгән срок чыккан көнгә кадәр 5 календарь көн эчендә билгеләнгән тәртиптә, күрсәтелгән юридик затлар тарафыннан Яр Чаллы шәһәре бюджетына күчерелергә тиеш.

Әлеге Нигезнамәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән юридик затлар тарафыннан сатуда җиңүченең алдан түләнгән акчасын кире кайтару сроклары бозылган очракларда, күрсәтелгән юридик затлар, срогы чыккан һәр календарь көн өчен түләнмәгән сумманың Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән һәм түләү датасына гамәлдә булган төп ставка пенясының йөз илледән бере күләмендә Яр Чаллы шәһәре бюджетына пеня түлиләр.»;

2) 2 нче кушымтада «_________ газетасының 20__ елның ________ _____ санында басылып чыккан һәм (яки) сайтларда» сүзләрен «рәсми сайтларда урнаштырылган» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 нче кушымтада «_________ газетасының 20__ елның ________ _____ санында басылып чыккан һәм (яки) сайтларда» сүзләрен «рәсми сайтларда урнаштырылган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин